| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

21.08.2025 № 921/1

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнарга бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибен раслау турында» 2025 елның 31 июлендәге 857 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнарга өстәмә социаль ярдәм чарасы күрсәтү максатларында, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының «Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнарга бер мәртәбә бирелә торган акчалата түләү бирү тәртибен раслау турында» 2025 елның 31 июлендәге 857 номерлы карарына (2025 елның 01 августындагы 860 номерлы кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

8 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2025 елның 1 августыннан 2025 елның 31 августына кадәр барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.».

Махсус хәрби операциядә катнашу максатларында Россия Федерациясе Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт узу турында контракт төзегән гражданнарга күрсәтелгән карар белән расланган бер мәртәбә акчалата түләү бирү тәртибендә:

3.2 пункт. 3 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2. Контракт төзегән гражданнарга бер мәртәбә түләү 2025 елның 01 августыннан 31 августка кадәр башкарылырга тиеш.».

2. Әлеге карар редакциясендәге Нигезләмәнең гамәлдә булуы 2025 елның 1 августыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында

урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе җаваплылыгында калдырырга.

Җитәкче Ә.К. Габдуллин